ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.05.2017 № 502

2017 нчы елда Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районында балаларның
һәм яшьләрнең ялын оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 3 октябрендәге 709 номерлы «2017 елда Татарстан Республикасы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында физик культураны, спортны, туризмны үстерү һәм яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 31 декабрендәге 1085 номерлы карары нигезендә, 2017 нчы елда балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балалар һәм яшьләр ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республиикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2017 нчы елда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча чаралар планын расларга (1 нче кушымта).
2. Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия составын расларга (2нче кушымта).
3. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга кабул итү комиссиясе составын расларга (3 нче кушымта).
4. Белем бирү оешмалары, яшүсмерләр клублары, яшьләр үзәкләре, йорт яны территорияләре базасында балалар мәйданчыклары исемлеген расларга һәм аларның эшләрен 2017 елның 1 июненнән 2016 елның 30 августына кадәр тәэмин итәргә (4 нче кушымта).
5. Расларга:

5.1. Балаларның ялын оештыру һәм көндез белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган лагерьларда аларны савыктыру планы (5 нче кушымта);

5.2. Балаларның ялын һәм аларны хезмәт һәм ял лагерьларында сәламәтләндерүне оештыру планы (6 нчы кушымта);

5.3. Муниципаль яисә дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең, коммерция һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләренең балаларының ялын һәм аларны савыктыруны оештыру планы (7 нче кушымта);

5.4. Шәһәр яны лагерьларының, палатка тибындагы лагерьларның профильле сменаларында катнашучы балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру планы (8 нче кушымта).

6. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты сменаларын оештыручылары булган лагерьларда юлламалар бирүгә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризалары рәвешләрен расларга (9-12 нче кушымталар).

7. Муниципаль лагерьларда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга норматив чыгымнарның 20% күләмендә ата-аналар түләве күләмен билгеләргә.

8. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (Зарипов Р.И.):

8.1. Лагерьларда профилактик учетларда торучы яшүсмерләр, шулай ук социаль куркыныч һәм авыр тормыш хәлендә булган балалар өчен квота (беренче сыйныфтан унынчы сыйныфка кадәр укучылар) күздә тотып көндезге ял итү лагерьларында сменалар эшен тәэмин итәргә;

8.2. Гомуми белем бирү оешмалары базасында көндезге ял итү лагерьларында сменаларның эшен хәрби-патриотик юнәлештә, аларда чакырылыш комиссияләре рекомендацияләре буенча армиягә кадәрге яшьтәге егетләр ялын һәм сәламәтләндерүне (беренче сыйныфтан унынчы сыйныфка кадәр укучылар) тәэмин итүне күздә тотып оештырырга;

8.3. Каникуллар чорында өстәмә белем бирү оешмаларының эшен тәэмин итү;

8.4. Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгында һәм Алабуга муниципаль районының тарихи урыннарында, шулай ук «Борынгы Болгар» тарих-архитектура музей-тыюлыгында һәм «Свияжск утрау-шәһәре« музей-тыюлыгында балаларның булуын гамәлгә ашырырга;

8.5. 2017 елның 1 июненнән 30 августка кадәр балигъ булмаганнарның хокук бозуларны профилактикалау системасы субъектлары белән берлектә «Куркынычсыз җәй-2017» операциясен үткәрергә;

8.6. Мөмкинлекләре чикләнгән балаларны кимендә 35% җәлеп итәргә, аларның ата-аналарын ата-аналар түләү взносларыннан азат итәргә;

8.7. «Алабуга шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе белән 500 кешедән торган 14-18 яшьлек балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру буенча уртак эшчәнлек турында килешүләр төзергә;

8.8. Җәйге чорда балигъ булмаган гражданнарны эшкә урнаштыру исемлеген формалаштырырга;

8.9. Алабуга муниципаль районының авыл җирлекләрендә гомуми белем бирү оешмалары базасында хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар эшен оештыру.

9. Алабуга муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ял оешмалары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- ял оешмаларында балалар һәм яшьләрнең комплекслы иминлеген тәэмин итү;

- балаларның иминлеген һәм сәламәтлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән санитар-эпидемиологик, хокук тәртибе, санитар-экологик һәм янгын куркынычсызлыгы иминлеге, балаларның суда ял иткәндәге иминлеге һәм ял итү урыннарында аларны сәламәтләндерү буенча чаралар комплексын эшләү һәм үткәрү;

- балаларның һәм яшьләрнең ял итү оешмаларында ял итүче балаларны коену өчен билгеләнгән су объектлары төбен водолаз тикшерүне һәм чистартуны тәэмин итәргә;

- балалар һәм яшьләрнең ял итү оешмаларында булган бәхетсезлек очракларыннан балаларны һәм яшьләрне ирекле иминләштерүне оештырырга;

- балаларның һәм яшьләрнең ял оешмаларын квалификацияле персонал, һөнәри әзерлек дәрәҗәсе булган педагогик кадрлар белән тәэмин итәргә;

- балаларны һәм яшүсмерләрне физик тәрбия һәм чыныктыруны, гигиеник тәрбия бирүне тәэмин итәргә, наркомания, тәмәке тартуны кисәтергә, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрергә;

- балаларның һәм яшьләрнең, аларның мәнфәгатьләрен һәм психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып, эчтәлекле ял итү өчен шартлар тудырырга;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә җинаять эзәрлекләве факты булу (булмау) очракларын тикшерүне гамәлгә ашырырга;

- ачылганчы 14 көн кала балаларның ял итү оешмалары территорияләрен һәм 50 метр зонаны талпанга каршы эшкәртергә;

- хезмәтне саклау буенча балаларның ял оешмалары педагогик кадрларын, янгын-техник минимум һәм барлык хезмәткәрләрнең гигиеник әзерлеге программалары буенча укытуны оештырырга;

- «Строитель (Яшь төзүче)» БСЛ, «Лесная сказка (Урман әкияте)» БСЛ, «Космос» санаторий-профилакториясе 2017 елның 15 маена кадәр куркынычсызлык паспортын рәсмиләштерергә;

10. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (Крылов А. М.), “Балаларны спорт-сәламәтләндерү лагерьлар комплексы» муниципаль бюджет учреждениесенә (Умеркина Н.Н.):

10.1. Шәһәр яны ял лагере эшен оештырырга: «Яшь төзүче» БСЛ - сменаларның дәвамлылыгы – 21 көн (җәйге каникулларда), 7 көн (язгы/көзге каникулларда), «Урман әкияте» БСЛ профильле сменаларның эшен оештыру – 18 көн (җәйге каникулларда);

10.2. Ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны;
инвалид балаларны;
сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, ягъни физик һәм психик үсешендә кимчелекләр булган балаларны;
кораллы һәм милләтара конфликтлар, экологик һәм техноген катастрофалар, стихияле бәхетсезлекләр корбаннары булган балаларны;
качаклар һәм мәҗбүри күчеп кайтучылар гаиләләрендәге балаларны;

экстремаль шартларда калган балаларны;
көчләү корбаннары булган балаларны;
тәрбияләү колонияләрендә иректән мәхрүм ителеп, җәза срогы узучы балаларны;
тәрбияләүнең, белем бирүнең аерым шартларына һәм махсус һәм педагогик якын килүне таләп итүгә мохтаҗ булган, девиантлы (җәмгыять өчен куркыныч) тәртипле гомуми белем бирүче оешмаларда булган балаларны;
килеп туган шартлар нәтиҗәсендә тормыш эшчәнлеге объектив төстә бозылган һәм мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә ярдәме белән әлеге хәлләрне җиңә алмаучы балаларны;
җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән ким булган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендә кабул ителгән «Татарстан Республиксында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 542 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә балага айлык пособие алучы гаиләләрдәге балаларны;

социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ булган балигъ булмаганнар өчен махсус оешмаларда тәрбияләнүчеләрне;

социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балаларны (алга таба – авыр тормыш хәлендә калган балалар);

10.3. Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыруның иң яхшы вариатив программасы дип аталган республика конкурсында катнашу;

10.4. Шәһәр читендәге ял лагерьларының медицина кабинетларын медицина җиһазлары, дару чаралары һәм медицина әйберләре белән «Сәламәтләндерү һәм оешкан ял вакытында балигъ булмаганнарга медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында 2012 елның 16 апрелендәге 363-н номерлы РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш Министрлыгы боерыгы нигезендә җиһазландырырга.

11. Алабуга муниципаль районы территориясендә 2017 елның 1 июненнән 25 августына кадәр «Яшүсмер – 2017» ведомствоара профилактик операциясен игълан итәргә.

12. Алабуга муниципаль районында Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясенә:

12.1. «Яшүсмер – 2017» ведомствоара профилактик операциясен уздыруны тәэмин итәргә.

12.2. Профилактик учетларда торучы балалар һәм яшүсмерләрнең, шулай ук социаль куркыныч хәлдә булган балалар (тормыш яки сәламәтлек өчен куркыныч тудыручы яки балаларны тәрбияләү һәм карап тоту таләпләренә җавап бирмәүче шартларда), авыр тормыш хәлендә булган балаларның җәйге ялын мониторинглауны гамәлгә ашырырга һәм мәгълүматларны 2017 елның 1 июненә кадәр балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә җибәрергә;

12.3. Профилактик учетларда торучы балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру формаларын 100% ка тәэмин итәргә;

12.4. Социаль куркыныч хәлдә булган балалар (тормыш яки сәламәтлек өчен куркыныч тудыручы яки балаларны тәрбияләү һәм карап тоту таләпләренә җавап бирмәүче шартларда) һәм авыр тормыш хәлендә калган балаларны, шул исәптән гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларны вакытлыча һәм даими эшкә урнаштыру мониторингын гамәлгә ашырырга;

12.5. Алабуга муниципаль районында Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе утырышында балаларның җәйге ялын оештыру буенча эш нәтиҗәләрен, «Яшүсмер – 2017» ведомствоара профилактик операциясенә йомгак ясау һәм аларны 2017 елның 20 сентябренә кадәр балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә җибәрергә.

13. «Алабуга халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (Демина Ю.Л.) тәкъдим итәргә:

13.1. 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган балаларны укудан буш вакытларында эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында халыкка мәгълүмат җиткерү эшен оештырырга;

13.2. Балигъ булмаган балаларны җәйге чорда хокук бозуларны профилактикалау системасы субъектларында профилактик исәптә торучы гражданнарны һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияләрне беренче чиратта эшкә урнаштыруны тәэмин итәргә;

13.3. Балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытларында эшкә урнаштыруны оештыру буенча килешүләр төзергә.

14. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына тәкъдим итәргә (Садыйкова Э. И.):

14.1. 2017 елга җирле бюджетта балалар һәм яшьләрне сәламәтләндерү кампаниясен оештыру буенча каралган расланган чаралар чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә;

14.2. Татарстан Республикасы бюджетыннан гомуми суммасы 13 373 100 сум бүлеп бирелгән субсидияләр хисабына 2017 елда балалар һәм яшьләр ялын финанслауны гамәлгә ашырырга.

15. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр,
пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә балага айлык пособие алучы булып торучы Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбән булган гаиләләрдәге балаларның ялын оештыруны тәэмин итәргә; социаль реабилитацияләүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган оешмаларда тәрбияләнүчеләр ялын оештыру, балигъ булмаганннар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрендә һәм эчке эшләр органнарының

балигъ булмаганннар эшләре бүлекчәләрендә исәптә торучы , күзәтүчесез һәм сукбай балалар өчен ял оешмаларында урыннар бүлеп бирергә.

16. «Алабуга балалар йорты» дәүләт бюджет белем бирү учреждениесенә (Шәрипова Г.Р.) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәһәр яны лагерьларында тәрбияләнүчеләрнең ялын оештырырга тәкъдим итәргә.

17. «Алабуга урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесенә (Усманов А.К.), «Түбән Кама»\ «Милли паркы» Федераль дәүләт бюджет учреждениесенә (Имамов А.Г.) җәйге сәламәтләндерү кампаниясе дәвамында урман-техник чараларын, урман территорияләрен санитар чистартуны тәкъдим итәргә.

18. Казан (Идел буе) Федераль университетының Алабуга шәһәрендәге филиалына (Мерзон Е.Е.), Алабуга политехник көллияте (С.В. Соколова), Алабуга медицина училищесы (Р.А. Әхмәтшин), Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте (А.Г. Әкбәрова) студентлары ялын, аларны сәламәтләндерүне һәм мәшгульлекне оештырырга тәкъдим итәргә.

19. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (Зарипов Р.И.), «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (Крылов А.М.), Казан (Идел буе) Федераль университетының Алабуга шәһәрендәге филиалына (Мерзон Е.Е.), «Космос» шифаханә-профилакториясенә тәкъдим итәргә:

19.1. Шәһәр читендәге ял лагерьларында эшләүчеләргә лагерьның исеме, вазыйфасы, смена вакыты күрсәтелгән медицина күзәтүе өчен юнәлешләр бирүне тәэмин итәргә;

19.2. Лагерьларның медицина кабинетларын кирәкле медицина җиһазлары, дару чаралары һәм медицина әйберләре белән РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Сәламәтләндерү һәм оештырылган ял вакытында балигъ булмаганнарга медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 нче елның 16 апрелендәге, 363-н номерлылы боерыгы нигезендә җиһазландырырга;

19.3. Балаларның ял итү һәм аларны савыктыру оешмаларында медицина кабинетларын лицензияләү буенча чаралар күрергә.

20. Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлегенә (Ю. Н. Пономарев) балаларны шәһәр читендәге ял лагерьларына кадәр йөртүне оештыра торган транспорт чараларының юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенең патруль автомобильләре белән тәэмин итүне тәэмин итәргә.

21. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең (Крылов А.М.) «Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының «Җәй» балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерүне, ял иттерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә үз вакытында барлык типтагы лагерьларны ачу графигы, оператив мәгълүмат һәм

балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыру буенча йомгаклау финанс хисаплылыгын оештыру турында мәгълүмат тапшырырыга

22. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

22. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә (Крюков С.А.) 2017 елда район территориясендә балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру, аларны сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру турындагы мәгълүматны халыкка җиткерергә, аны массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән Алабуга муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

23. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Рыбаковага йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“______” _______ ____ел

карарына 1 нче кушымта

**2017 нчы елда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча чаралар планы**

| № | Чараның исеме | Үтәлү вакыты | Үтәүчеләр |
|---|---|---|---|
| | **Гомуми белем бирү оешмаларында балаларның савыктыргыч һәм сәламәт ялы** | | |
| 1 | Белем бирү оешмасы тарафыннан көндезге лагерь сменаларын оештыру | Март-апрель<br>Июнь-июль | Зарипов Р.И. |
| 2 | Ял һәм хезмәт лагередә эш сменаларын оештыру | Июнь | Зарипов Р.И. |
| 3 | Палатка тибындагы лагерьләрдә профильле сменалар оештыру:<br>“Яшь эколог” (БЭБҮ) 03.06-09.06 2017 ел<br>“Яшь армияче” (БМҮ) 23.07-29.07 2017 ел | Июнь-июль | Зарипов Р.И. |
| 4 | Белем бирү оешмалары оештырган көндезге лагерьләрдә балалар белән эшләү өчен кадрлар әзерләү | Февраль-май | Зарипов Р.И. |
| 5 | Каикуллар чорында өстәмә белем бирү оешмалары җирлегендә кызыксынучан балалар берләшмәсе эшен оештыру | Ел буена | Зарипов Р.И. |
| 6 | Балигъ булмаганнар тарафыннан хокук бозу һәм сукбайлыкны булдырмау максатыннан чыгып, аларны төрле оешмаларда җәйге каникуллар чорында эш урыны белән тәэмин итү | Май-сентябрь | Зарипов Р.И. |
| 7 | Балаларныд “ИнтелЛето”көндезге ял һәм савыктыргыч лагерендәге ялы сменасы:12.06-02.07.2017 ел | Июнь-июль | Аукцион нәтиҗәсе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | буенча |
| 8 | Балаларның тәүлеклек савыктыргыч ял лагере (ССЛ “Буревестник”). Профильле сменалар:<br>23.03-31.03 20197ел<br>31.10-06.11 2017 ел<br>1 смена-01.06-18.06 2017 ел<br>2 смена-02.08-19.08 2017 ел<br>3 смена-27.10-04.01 2017 ел | Март, июнь-август,октябрь-ноябрь | Мерзон Е.Е. (килешү буенча) |
| 9 | Палаткалы типтагы профильле лагерь сменаларын оештыру: “Буревестник” (КФУ)-14.06-21.06 2017 ел | Июнь | Мерзон Е.Е. (килешү буенча) |
| **Ведомство карамагындагы МБК “Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, яшьләр һәм спорт идарәсе” оешмаларында балаларның сәламәтлеген ныгытуы һәм ялы** | | | |
| 10 | Б.Я.Л. “Яшь төзүче”, “Урман әкияте”нең материаль-техник нигезен ныгыту чараларын уздыру | Январь-май | Крылов А.М. |
| 11 | Шәһәр чите ял лагере “Яшь төзүче”дә балаларның савыктыргыч ялы<br>Профильле сменалар:25.05-31.05 2017 ел<br>1 смена-03.06-23.06 2017 ел<br>2 смена-02.07-22.07 2017 ел<br>3 смена-01.08-21.08 2017 ел | Май,<br>Июнь-август | Крылов А.М. |
| 12 | Шәһәр чите ял лагере “Урман әкияте”ндә балаларның савыктыргыч ялы:<br>1 смена-29.06-16.07 2017 ел<br>2 смена- 01.08-18.08 2017 ел<br>Профильле сменалар:<br>18.07-24.07 2017 ел (этно-мәдәни смена)<br>28.10-03.11 2017 ел | Июнь-август, ноябрь | Крылов А.М. |
| 13 | Палаткалы типтагы лагерьдә профильле сменалар оештыру: “Патриот” (Форпост) 24.06-30.06 2019 ел | Июнь | Крылов А.М. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 14 | Рәсәй Федерациясенең һәм Татарста Республикасының сааторно-курортлы оешмаларында һәм лагерьләрендә авыр тормыш шартларында яшәүче, социаль реабилитациягә мохтаҗ булган һәм махсус учреждениеләрдә тәрбияләнүче балаларның сәламәтлеген ныгытучы савыктыргыч ялы | Ел буена | Крылов А.М. |
| 15 | Белем бирү оешмаларының балалар һәм яшьләрнең сәламәтлеген ныгыту оешмалары белән берлектә эшләве | Ел буена | Зарипов Р.И.<br>Крылов А.М.<br>Таипова А.Р. |
| 16 | Йорт яны мәйданчыкларында балаларны ял иттерү чараларын оештыру һәм уздыру | Май-сентябрь | Зарипов Р.И.<br>Крылов А.М.Таипова А.Р. |
| **Мәдәният идарәсе ведомство карамагында булган оешмаларда балаларның савыктыргыч ялы** | | | |
| 17 | “Җәйге буяулар” иҗади проекты (мастер-класслар) | Май-август | Таипова А.Р. |
| 18 | “Китап ПАРК тукталышы”акциясе (Александр бакчасы) | Июнь-август | Таипова А.Р. |
| 19 | “Җәй боегу өчен түгел” (БИК) клубы эше | Июнь-август | Таипова А.Р. |
| 20 | “Китап сөючеләр” клубы эше (БКФ №3) | Июнь-август | Таипова А.Р. |
| 21 | “Китапның каникулы юк” клубы эше (ШКФ №5) | Июнь-август | Таипова А.Р. |
| 22 | “Кызыксынучаннар” клубы эше (ШКФ №6) | Июнь-август | Таипова А.Р. |
| 23 | “Урам китапханәсе” | һәрдаим | Таипова А.Р. |
| 24 | “Җәйнең китапча елмаюы” (ШМЙ алды мәйданы) | Июнь-август | Таипова А.Р. |
| 25 | “Китаплы җәй” (Георгиев паркы) | Июнь-август | Таипова А.Р. |
| 26 | Халыкара балаларны яклау көненә багышланга чаралар оештыру һәм уздыру | Июнь | Таипова А.Р. |
| 27 | Сәнгать мәктәбе укучылары өчен җәйге пленэрлар оештыру | Июнь | Таипова А.Р. |
| 28 | “Иллюзион”кинотеатры җирлегендә “Караш” киноклубы эше (якшәмбе) | Июнь-август | Таипова А.Р. |
| 29 | Китапханәләр һәм авыл мәдәният йортлары карамагында клублар һәм түгәрәкләр эшен оештыру | даими | Таипова А.Р. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **Сәламәтлек саклау оешмалары тарафыннан балаларның сәламәтлеген һәм ялын оештыру чаралары** | | | |
| 30 | Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсе вәкилләре тарафыннан медицина хезмәткәрләре, башлыклар, хезмәт күрсәтү персоналлары өчен балаларның ялына, сәламәтлегенә кагылышлы сораулар буенча семинарлар уздыру | Май | Әхмәтҗанов Ш.Г. (килешү буенча) |
| 31 | Балалар һәм яшьләрнең җәйге ялын оештыручыларны медицина тикшерүе уздыру | Апрель-август | Әхмәтҗанов Ш.Г. (килешү буенча) Даровских М.С. (килешү буенча) |
| 32 | Балалар бүлегедә хроник авырулардан дәваланучы балаларның сәламәтлеген ныгыту | Июнь-август | Әхмәтҗанов Ш.Г. (килешү буенча) |
| 33 | Каникуллар чорында вакытлыча эшкә урнашучы балигъ булмаганнарның сәламәтлеген тикшерү | Июнь-август | Әхмәтҗанов Ш.Г. (килешү буенча) |
| **Балалар һәм яшүсмерләрнең вакытлыча шогыле** | | | |
| 34 | Предприятие һәм оешмалар тарафыннан 14-18 яшьлек балигъ булмаганнарны вакытлыча эш урыны белән тәэмин итү | Январь-декабрь | Демина Ю.Л. (килешү буенча) |
| 35 | Каникуллар чорында дәүләт карамагында калган, ятим, авыр тормыш шартларында яшәүче 14-18 яшьлек балигъ булмаганнарны вакытлыча эш урыны белән тәэмин итү | Январь-декабрь | Демина Ю.Л. (килешү буенча) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 36 | 14-18 яшьлек балигъ булмаганнарга каникуллар чорына вакытлыча белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган хезмәт бригадаларына урнашу мөмкинлеге бирү (мисал өчен:кыр эшләре, мал карау, яшелләндерү, ремонт эшләре) | Июнь-август | Демина Ю.Л. (килешү буенча) |
| **Студентларның савыктыргыч ялы** | | | |
| 37 | Колледжның җәмәгать тормышында һәм укуда актив булган студентлар өчен Болгар, Свияжск шәһәрләренә экскурсия оештыру | Июнь | Соколова С.В. (килешү буенча) |
| 38 | Студетлар программасы буенча актив студентлар өчен җәйге стажировка узу мөмкинлекләрен булдыру | Апрель-октябрь | Мерзон Е.Е. (килешү буенча) |
| 39 | Татарстан Республикасы шәһәрләре буйлап экскурсия оештыру | Декабрь | Ахметшин Р.А. (килешү буенча) |
| 40 | Студентларның хезмәт лагерьләрен оештыру | Май-сентябрь | Мерзон Е.Е. (килешү буенча) Соколова С.В. (килешү буенча) |
| 41 | “Профактив мәктәбе”-студентларның җәйге ялы | Июнь-август | Мерзон Е.Е. (килешү буенча) |
| 42 | СОЛ “Буревестник”та студентларның ялын оештыру | Июнь-сентябрь | Мерзон Е.Е. (килешү буенча) |
| 43 | Балалар һәм яшьләрнең савыктыргыч ялын оештыруны тәэмин итү: | Февраль-ноябрь | Умеркина Н.Н. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - Алабуга муниципаль районының савыктыргыч кампанияләр өчен ял итәргә теләк белдергән балалар исемлеген туплауны оештыру;<br>-муниципальһәм дәүләт учреждениеләре башлыклары белән киңәшмәләр оештыру;<br>-балалар ялын оештыруга муниципаль контрактлар, килешүләр төзү;<br>-финанс-хисапны формалаштыру | | |

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“______” ______ ____ел
карарына 2

нче кушымта

2017 НЧЕ ЕЛДА
БАЛАЛАР hӘМ ЯШЬЛӘРЕНЕҢ ЯЛЫН ОЕШТЫРУЧЫ ВЕДОМСТВОАРА КОМИССИЯНЕҢ
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Рыбакова Людмила Николаевна | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социальсораулар буенча урынбасары, ведомтсвоара комиссиянең рәисе |
| Крылов Александр Михайлович | “Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты яшьләр һәм спорт эшләре белән идарә итү буенча ” МКУ башлыгы, ведомствоара комиссия рәисенең урынбасары |
| Зарипов Ривал Исмаәгыйл улы | “Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты белем бирү белән идарә итү буенча” МКУ башлыгы, ведомствоара комиссия рәисенең урынбасары |
| Пивторонис Юлия Анатольевна | Алабуга муниципаль районының яшьләр белән эшләү буенча белгеч (МБУ “ЯҮ БАРС”), ведомствоара комиссиянең сәркатибы |

Ведомствоара комиссиянең әгъзалары

| | |
|---|---|
| Садыкова Эльмира Ильдар кызы | Алабуга муниципаль районының финанс –бюджет палатасы рәисе (килешенү буенча) |
| Хәмидуллин Денис Фәрит улы | Алабуга муниципаль районының Перспектив социаль-экономик үсеше Палатасы рәисе (килешенү буенча) |
| Әхмәтҗанов Шәфкать Гарифҗан улы | ДАСУ “АҮРХ” (Алабуга район хастаханәсе) баш табибы(килешенү буенча) |
| Таипова Айгөл Риф кызы | “Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты мәдәнияте” МКУ башлыгы |
| Прохорова Светлана Викторовна | Татарстан Республикасының халыкнысоциальяклау бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| Пономарев Юрий Николаевич | Алабуга муниципаль районы буенча Рәсәйнең ЭЭМ бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| Вәлиев Илназ Миңнехамис улы | Алабуга муниципаль районы буенча Рәсәйнең ЭЭМ бүлегенең ЮХИДИ башлыгы (килешенү буенча) |
| Ябуров Александр Сергеевич | Алабуга муниципаль районы буенча күзәтү эшчәнлеге бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| Вдовин Сергей Петрович | Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районы |

| | |
|---|---|
| | һәм Алабуга шәһәрендә Роспотребнадзор идарәсенең ТБ башлыгы (килешенү буенча) |
| Даровских Максим Сергеевич | “Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районы һәм Алабуга шәһәрендә гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБСУ филиалының баш табибы (килешенү буенча) |
| Парунина Эльвира Кашафовна | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә һәм көнкүреш бүлеге мөдире |
| Руденко Гульзада Ракиповна | Алабуганың дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы директоры (килешенү буенча) |
| Умеркина Нурия Нурмухамедовна | АМР “БССЛ”МБУ директоры |
| Крюков Сергей Александрович | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы |
| Муллагалиева Гөлшат Равил кызы | ОАО “ТАМЕДИА”, “Алпресс” директоры (килешенү буенча) |
| Демина Юлия Леонидовна | ДКУ“Алабуга шәһәрендә халык шөгыле үзәге”директоры (килешенү буенча) |
| Назарова надеңда Георгиевна | Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районы буенча ББЭБ һәм УПВ Рәсәйнең ЭЭМ башлыгы (килешенү буенча) |
| Шантурина Ангелина Константиновна | Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты опека һәм попечителлек бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |
| Степанов Максим Александрович | Яр Чаллы ЗУЭСының Алабуга районы электр элемтәсе үзәге башлыгы (килешенү буенча) |
| Гончар Ольга Никоноровна | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы һәм Алабуга шәһәрендә ФМ  МС бүлеге җитәкчесе (килешенү буенча) |

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“_____” ______ ____ел
карарына 3 нче

кушымта

Балалар һәм яшьләрнең ял итү
оешмаларын кабул итү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Рыбакова Людмила Николаевна | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социальсораулар буенча урынбасары, ведомтсвоара комиссиянең рәисе |
| Әхмәтҗанов Шәфкать Гарифҗан улы | ДАСУ “АУРХ” (Алабуга район хастаханәсе) баш табибы(килешенү буенча) |
| Даровских Максим Сергеевич | “Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районы һәм Алабуга шәһәрендә гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБСУ филиалының баш табибы (килешенү буенча) |
| Вдовин Сергей Петрович | Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районы һәм Алабуга шәһәрендә Роспотребнадзор идарәсенең ТБ башлыгы (килешенү буенча) |
| Вәлиев Илназ Миңнехамис улы | Алабуга муниципаль районы буенча Рәсәйнең ЭЭМ бүлегенең ЮХИДИ башлыгы (килешенү буенча) |

| | |
|---|---|
| Ябуров Александр Сергеевич | Алабуга муниципаль районы буенча күзәтү эшчәнлеге бүлеге башлыгы (килешенү буенча) |

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“_____” ______ ____ел
карарына 5 нче
кушымта

Белем бирү оешмасы оештырган көндезге лагерьларда балаларның ялын оештыру һәм аларны савыктыру планы

| | Лагерьны оештыру өчен база (мәктәп) | Кеше саны | Көннәр саны (сменалар саны) | Юлламаның норматив бәясе-1 сум. | ТР бюджетыннан субсидия-мең сум. | Ата-ана взнос Мең сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Җәйге чорда | | | | | | |
| 1 | «1 НЧЕ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» белем бир үмуниципаль бюджет учреждениесе | 122 | 21 (1). | 3 200,82 | 331,90 | 78,08 |
| 2 | «2 НЧЕ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 125 | 21 (2). | 3 200,82 | 340,10 | 80,00 |
| 3 | «3 НЧЕ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 100 | 21 (1). | 3 200,82 | 272,07 | 64,00 |
| 4 | «4 нче гимназия» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 90 | 21( 1) | 3 200,82 | 244,86 | 57,60 |
| 5 | «5 НЧЕ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 45 | 21 (1). | 3 200,82 | 122,43 | 28,80 |
| 6 | «6 НЧЫ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» муниципаль бюджет белем | 100 | 21 (2). | 3 200,82 | 272,07 | 64,00 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | бирү учреждениесе | | | | | |
| 7 | «8 НЧЕ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 200 | 21(1) | 3 200,82 | 544,14 | 128,00 |
| 8 | «9 НЧЫ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 100 | 21(1) | 3 200,82 | 272,07 | 64,00 |
| 9 | «10 НЧЫ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 305 | 21 (2). | 3 200,82 | 829,81 | 195,20 |
| 10 | 1 нче «Гимназия» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 50 | 21(1) | 3 200,82 | 136,03 | 32,00 |
| 11 | Алабуга муниципаль районы «2 нче гимназия» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 30 | 21(1) | 3 200,82 | 81,62 | 19,20 |
| 12 | Алабуга муниципаль районы «Бехтерев урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 15 | 21(1) | 3 200,82 | 40,80 | 9,60 |
| 13 | Алабуга муниципаль районы «Танай урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 35 | 21(1) | 3 200,82 | 95,22 | 22,40 |
| 14 | Алабуга муниципаль районы «Поспелово урта | 15 | 21 (1). | 3 200,82 | 40,80 | 9,60 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | | | | | |
| 15 | «Иске Күклек урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 7 | 21(1) | 3 200,82 | 20,05 | 4,48 |
| 16 | «Лекарево урта мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе | 12 | 21(1) | 3 200,82 | 32,65 | 7,68 |
| 17 | «Яковлево урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 15 | 21(1) | 3 200,82 | 40,80 | 9,60 |
| 18 | «Костенеево урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 12 | 21 (1). | 3 200,82 | 32,65 | 7,68 |
| 19 | Алабуга муниципаль районы «Олы Шүрнәк урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 12 | 21(1) | 3 200,82 | 32,65 | 7,68 |
| 20 | Алабуга муниципаль районы «Иске Юраш урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 18 | 21 (1). | 3 200,82 | 48,97 | 11,52 |
| 21 | «Морт урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 12 | 21 (1). | 3 200,82 | 32,65 | 7,68 |
| 22 | «11 нче санлы Тарлау урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 10 | 21 (1). | 3 200,82 | 27,43 | 6,40 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | **Көндезге лагерьлар буенча нәтиҗәләр** | 1430 | | | 3 890,60 | 915,20 |
| | Конкурс йомгаклары буенча (ИнтелЛето) | 170 | 21 (1). | 3072,30 | 443,95 | 104,45 |
| | **Барлыгы** | | | | | |
| **Калган чорда** | | | | | | |
| 1 | «2 НЧЕ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 35 | 7 (1). | 1 066,94 | 31,74 | 7,47 |
| 2 | «3 НЧЕ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 30 | 7(1). | 1 066,94 | 27,21 | 6,41 |
| 3 | «6 НЧЫ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе | 45 | 7 (1). | 1 066,94 | 40,81 | 9,61 |
| 4 | «9 НЧЫ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 30 | 7(1). | 1 066,94 | 27,21 | 6,41 |
| 5 | «10 НЧЫ НОМЕРЛЫ МӘКТӘП» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 45 | 7(1). | 1 066,94 | 40,81 | 9,61 |
| | **Барлыгы** | **185** | | | 167,78 | 39,51 |

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“_____” ______ ____ел
карарына 6 нчы
кушымта

Хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның
ялын һәм аларны савыктыруны оештыру планы
.

| | Лагерьны оештыру өчен база (мәктәп) | Кеше саны | Көннәр саны (смена саны) | Юлламаның норматив бәясе-сум. | ТР бюджетыннан субсидияләр, мең сум. | Җирле бюджет |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Алабуга муниципаль районы «Бехтерев урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 23 | 18 (1). | 2 743,56 | 63,10 | |
| 2 | Алабуга муниципаль районы «Танай урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 35 | 18 (1). | 2 743,56 | 96,02 | |
| 3 | Алабуга муниципаль районы «Поспелово урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 23 | 18 (1). | 2 743,56 | 63,10 | |
| 4 | «Иске Күклек урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 5 | 18 (1). | 2 743,56 | 13,72 | |
| 5 | «Лекарево урта мәктәбе» | 16 | 18 (1). | 2 743,56 | 43,90 | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе | | | | | |
| 6 | «Яковлево урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 23 | 18 (1). | 2 743,56 | 63,10 | |
| 7 | «Костенеево урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 16 | 18 (1). | 2 743,56 | 43,90 | |
| 8 | Алабуга муниципаль районы «Олы Шүрнәк урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 16 | 18 (1). | 2 743,56 | 43,90 | |
| 9 | Алабуга муниципаль районы «Иске Юраш урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 17 | 18 (1). | 2 743,56 | 46,64 | |
| 10 | «Морт урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 16 | 18 (1). | 2 743,56 | 43,90 | |
| 11 | «11 нче санлы Тарлау урта мәктәбе» белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе | 10 | 18 (1). | 2 743,56 | 27,44 | |
| | **Барлыгы** | **200** | | | **548,71** | |

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“______” _______ ____ел

карарына 7 нче кушымта

Муниципаль яисә дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләренең шәһәр яны лагерьларында балаларның ялын оештыру һәм аларны савыктыру планы

| | Лагерь исеме | Кеше саны | Көннәр саны (смена саны) | Путевканың норматив бәясе | ТР бюджетыннан субсидия-мең сум. | Оешмалар чаралары | Ата-аналар взносы. Мең сум | Җирле бюджет |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | "Яшь төзүче" БЯЛ МБУ, шул исәптән. | 500 | 21 (4) | 15747,90 | 5099,32 | 956,12 | 1424,25 | 1615,73 |
| | - муниципаль һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең балалары | 350 | | 15747,90 | 4143,20 | | 974,86 | 1131,01 |
| | - коммерцияле оешмалар хезмәткәрләренең балалары | 150 | | 15747,90 | 956,12 | 956,12 | 449,39 | 484,72 |
| 2 | МБУ МБУ Барс | 25 | 21 (4) | 15747,90 | 318,70 | | 74,99 | 0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| . | | | | | | | | |
| | - муниципаль hәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең балалары | 25 | | 15747,90 | 318,70 | | 74,99 | 80,78 |

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“_____” ______ ____ел
карарына 8 нче
кушымта

Шәһәр яны лагерьларының, палатка тибындагы лагерьларның профильле сменаларында катнашучы балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру планы

**Палатка типтагы лагерьлар**

| Палатка лагерь исеме | Үткәрү территориясе | Кеше саны | Көннәр саны (сменалар саны) | Юлламаның норматив бәясе-сум. | Финанслау чыганаклары, мең сум. | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | ТР субсидиясе | Ата-ана кертемнәре | Жирле бюджет |
| "Патриот" палаткалы лагеренда профильле смена (Форпост) | Алабуга районы | 40 | 7 (1). | 6176,72 | 200,08 | 47,06 | 0 |
| "Юнармеец" палатка тибындагы лагерьда профильле алмаш | Алабуга районы | 30 | 7 (1). | 3205,80 | 0 | 16.029 | 80.145 |
| "Яшь техник" палатка тибындагы лагерьда профильле алмаш | Алабуга районы | 30 | 7 (1). | 3205,80 | 0 | 16,029 | 80.145 |
| "Бригантина" палатка тибындагы лагерьда профильле смена (Юлдаш) | Алабуга районы | 40 | 7 (1). | 6176,72 | 200,08 | 47,06 | 0 |
| Барлыгы | | 140 | | | | | |

**Шәһәр яны лагерьлары**

| | Лагерь исеме | Кеше сан | Көннәр саны | Юлламаның норматив | ТР бюджеты | Вакыйга мең сум. | Жирле бюд |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ы | (смена саны) | бәясе, сум. | ннан субсидияләр, Мең сум | | жет |
| | | | **Җәйге чорда** | | | | |
| 1. | "Урман әкияте " БЯЛ МБУ | 150 | 18 (4) | 13478,72 | 1636,70 | 385,10 | 484,72 |
| | | | **Көзге-кышкы чорда** | | | | |
| 1. | "Яшь төзүче" БЯЛ МБУ | 150 | 7 (1). | 5241,73 | 636,49 | 149,76 | 484,72 |
| 2. | "Буревестник" КФУ | 50 | 7 (1). | 5241,73 | 212,16 | 37,44 | |

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“_____” ______ ____ел

карарына 9 нчы

кушымта

Муниципаль (дәүләт) учреждениенең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә

гр. _____________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
паспорт
бирелгән:_____________________________
______________________________________________________________________,
яшәү адресы: ____________________________________________________,
теркәлү адресы
телефоны: _____________________________

**Гариза**

2017 елда минем балама шәһәр яны ял лагерена юллама бирүне сорыйм ___________ 2017 елда
_____________________________________________________________________
(Баланың Ф.И.А.и.)
укыту-чылар ____________________________________________________
(мәктәп, сыйныф)

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:
1) мөрәҗәгать итүченең паспорты һәм паспортның барлык тутырылган битләренең күчермәләре;
2) бала туу турында таныклык күчермәсе (паспорты, әгәр бала 14 яшькә җиткән булса)

(гариза бирүченең имзасы)
2021 ел

Гариза 2017 елның "_____"________________" кабул ителгән.

_______________________________________________________
(вазыйфасы) (Ф.И.А.и.)
_______________________________________________________
гариза кабул иткән затның имзасы

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
“_____” ______ ____ел

карарына 10 нчы кушымта

Алабуга муниципаль районы белем бирү оешмасының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә

гр. _____________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

паспорт
бирелгән:____________________________
_______________________________________________________________________,
яшәү адресы: ____________________________________________________________,
теркәлү адресы
телефоны: ______________________________

**Гариза**

______2017 елдан алып ______2017 елга кадәр баламга белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерьга юллама бүлеп бирүегезне сорыйм.

_______________________________________________________________________
(Баланың Ф.И.А.и.)
укыту-чылар ____________________________________________________
(мәктәп, сыйныф)

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:
1) алучының паспорты һәм паспортның барлык тутырылган битләренең күчермәләре;
2) бала туу турында таныклык күчермәсе (паспорты, бала 14 яшькә җиткән булса).

(гариза бирүченең имзасы)
2021 ел

Гариза 2017 елның "_____"________________" кабул ителгән.

_______________________________________________________
(вазыйфасы) (Ф.И.А.и.)
_______________________________________________________
гариза кабул иткән затның имзасы

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
"______" ______ ____ел
карарына 11 нче кушымта

Вәкаләтле органга йә коммерция (коммерциягә карамаган) оешмасының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә

гр. __________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
паспорт _________ N___________________________
бирелгән:_____________________________
_______________________________________________________________________,
яшәү адресы: ____________________________________________________________,
теркәлү адресы
телефоны: ______________________________

**Гариза**

2017 елда минем балама шәһәр яны ял лагерена юллама бирүне сорыйм ___________
2017 елда

______________________________________________________________

(Баланың Ф.И.А.и.)
укыту-чылар _______________________________________________
(мәктәп, сыйныф)
Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:
1) алучының паспорты һәм паспортның барлык тутырылган битләренең күчермәләре;
2) бала туу турында таныклык күчермәсе (паспорты, әгәр бала 14 яшькә җиткән булса)

(гариза бирүченең имзасы)
2021 ел

Гариза "_____"_______________ 20 ел.

__________________________________________________
(вазыйфасы) (Ф.И.А.и.)
__________________________________________________
гариза кабул иткән затның имзасы

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
"______" ______ ____ел
арарына 12 нче кушымта

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына

гр. _______________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
паспорт _________ N__________________________
бирелгән:____________________________
________________________________________________________________,
яшәү адресы: ______________________________________________________,
теркәлү адресы
телефоны: ____________________________

**Гариза**

______2017 елдан алып ______2017 елга кадәр минем балама шәһәр яны ялы лагеренең (палатка тибындагы лагерь) профиль сменасына юллама бирүне сорыйм
______________________________________________________________

(Баланың Ф.И.А.и.)
укыту-чылар _______________________________________________
(мәктәп, сыйныф)
Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:
1) алучының паспорты һәм паспортның барлык тутырылган битләренең күчермәләре;
2) бала туу турында таныклык күчермәсе (паспорты, әгәр бала 14 яшькә җиткән булса)

(гариза бирүченең имзасы)
2021 ел

Гариза "_____"_______________ 20 ел.

_____________________________________________________

(вазыйфасы) (Ф.И.А.и.)

_____________________________________________________

гариза кабул иткән затның имзасы